**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.10.2024 Балык Бистәсе штп. №312пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган аерым категория гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 23.01.2024 №63 Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 №273-ФЗ Федераль законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 02.07.2019 №546 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында 18 яшькә кадәр яисә 23 яшькә кадәр, әгәр ул белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә укыган очракта, өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләр өчен, балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү (алга таба – ата-аналар түләве) билгеләнгән күләмнән 50 процентка киметелә дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
3. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге муниципаль казна учреждениесе башлыгына әлеге карарда күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын күрсәтүне оештыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары мөрәҗәгать итүченең 23 яшькә кадәрге гаилә әгъзаларын урта һөнәри яисә югары белем бирү мәгариф оешмасында көндезге бүлектә уку факты турында

уку урыныннан ел саен бирелә торган белешмә нигезендә билгеләнә дип билгеләргә.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 ноябреннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов